Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.03.2022 ел Менделеевск ш. №178

Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы,
ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасы әзерлеген
комплекслы тикшерү һәм Менделеевск муниципаль
районына хәбәр итү системалары
техник чаралары торышын бәяләү
буенча комиссия төзү турында

Россиянең ГТХМ һәм Россия Цифрлы үсеш министрлыгының «Халыкка хәбәр итү системалары турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 578/365 номерлы боерыгы, Татартсан ГТХМ, Татарстан Цифрлы үсеш министрлыгының «Татарстан Республикасы халкына хәбәр итү системаларына эксплуатация-техник хезмәт күрсәтүне оештыру нигезләмәсен раслау турында» 2020 елның 24 июлендәге П/504/414 номерлы боерыгы һәм халыкка хәбәр итү муниципаль системасының һәм ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасының әзерлеген комплекслы тикшерүне, хәбәр итү системасының техник чаралары торышын бәяләүне оештыру максатларында Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы, ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасы әзерлеген комплекслы тикшерү һәм Менделеевск муниципаль районына хәбәр итү системасының техник чаралары торышын бәяләү буенча комиссия составын түбәндәгечә әзерләргә һәм расларга:
2. Комиссияләргә билгеләнгән вакытларда:
- халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы, ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасы әзерлеген, халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы паспорты һәм халыкка ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасы (КСЭОН) булу, техник хезмәт күрсәтү (ТО-2) техник хәбәр итү чаралары үткәрүне комплекслы тикшерүләр уздырырга;

- тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль хәбәр итү системасы, шул исәптән ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасы әзерлеген комплекслы тикшерү нәтиҗәләре буенча акт, Менделеевск муниципаль районына хәбәр итү системасының техник торышын бәяләү нәтиҗәләре буенча акт әзерләргә;

- таратып җибәрү исәбе буенча карарны вазыйфаи затларга җиткерергә.

3.Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, ТКХ һәм инфраструктура үсеше буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.И.Беляев

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 16 мартындагы 178 номерлы
карарына кушымта

Халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасы, ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасы әзерлеген комплекслы тикшерү һәм Менделеевск муниципаль районына хәбәр итү системасының техник чаралары торышын бәяләү комиссияләре составы

Комиссия рәисе:

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

Комиссия әгъзалары:

«Менделеевск муниципаль районының Гражданлык яклау идарәсе» МКУ җитәкчесе (килешү буенча)

ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Менделеевск муниципаль районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Менделеевск район электр элемтәсе бүлеге (РУЭС) баш инженеры

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе 86- янгын сүндерү һәм коткару бүлегенең 15- эзләү-коткару отряды башлыгы